РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ
ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮ ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
“ЯР ЧАЛЛЫ ДӘҮЛӘТ ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ”
ФИЛОЛОГИЯ ФАКУЛЬТЕТЫ
РУС ҺӘМ ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ КАФЕДРАСЫ

# Татар теле һәм әдәбияты, аларны укыту методикасы буенча чыгарылыш квалификация эше

**(белем алучылар өчен методик кулланма)**

# Выпускная квалификационная работа по татарскому языку и литературе, методик их преподавания

**(методическое пособие для обучающихся)**

**Яр Чаллы, 2023**

Методик кулланма рус һәм татар филологиясе кафедрасы утырышында расланды

Төзүче: филология фәннәре кандидаты Р.И. Хаҗиев

Фәнни мөхәррир: филология фәннәре кандидаты, доцент Р.Р. Галиуллин

Рецензентлар:
филология фәннәре докторы, доцент В.Ф. Макарова
филология фәннәре кандидаты, доцент Р.А. Закиров

**Татар теле һәм әдәбияты, аларны укыту методикасы буенча чыгарылыш квалификация эше (белем алучылар өчен методик кулланма)**: 44.03.05 Педагогик белем бирү (ике профиль буенча әзерләү) “Туган тел һәм әдәбият, Рус теле”, “Туган тел һәм әдәбият, Чит тел” профильләре буенча белем алучылар өчен методик кулланма / Төз. Р.И. Хаҗиев. – Яр Чаллы, 2023. – 15 б.

**Выпускная квалификационная работа по татарскому языку и литературе, методик их преподавания (методическое пособие для обучающихся)**: Методическое пособие для обучающихся по направлению подготовки 44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки) профили «Родной язык и литература, Русский язык», «Родной язык и литература, Иностранный язык» / Сост. Р.И. Хазиев. – Набережные Челны, 2023. – 15 с.

# Эчтәлек

Кереш........................................................................................................4
1. Хезмәт өчен тема сайлау...............................................................................5
2. Хезмәтне язу барышында материаллар туплау.............................................6
3. Чыгарылыш квалификация эшенең структурасына карата куелган таләпләр.....................................................................................................6
4. Сылтама һәм астөшермәләрне күрсәтү тәртибе...........................................11
5. Хезмәттә кулланылган чыганаклар исемлеген күрсәтү................................12
6. Хезмәтне техник яктан дөрес оештыру.......................................................13
7. Нормоконтроль уздыру тәртибе...................................................................13
Тәкъдим ителгән чыганаклар.........................................................................15

## Кереш

Югары уку йортын тәмамлап чыккан вакытта чыгарылыш квалификация эшен язу мәҗбүри шартларның берсе исәпләнә. Бу тип эшләр дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертелгәннәр.

Чыгарылыш квалификация эшен язу һәм яклау тәртибе – катлаулы фәнни-тикшеренү процессы. Моны истә тотып, чыгарылыш квалификация эшләре язу барышында махсус методик кулланма булдыру ихтыяҗы туа.

Әлеге кулланманың максаты – югары уку йортларының филология факультетларында белем алучыларга, фәнни җитәкчеләргә чыгарылыш квалификация эшләрен әзерләүдә методик ярдәм күрсәтү.

Кулланма ЮББ ФДБМУ “Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты”нда белем алучыларның фәнни-тикшеренү эшләренең нормоконтроле турындагы нигезләмәгә таянып эшләнде. Анда чыгарылыш квалификация эшләрен башкару өчен кирәк булган күрсәтмәләр, методик киңәшләр бирелде.

Әлбәттә, бу өлкәгә караган башка хезмәтләр дә бар. Мәсәлән, Ә.Г. Мусин, Р.Х. Мөхиярова, Ф.Г. Галләмов һәм башкаларның хезмәтләре. Әлеге хезмәтләр тәкъдим ителгән әдәбият исемлегендә урын алалар.

Методик кулланма югары уку йортларының филология факультетларында белем алучыларга чыгарылыш квалификация эшләрен башкаруда зур таяныч булыр дип уйлыйбыз.

## 1. Хезмәт өчен тема сайлау

Чыгарылыш квалификация эше темалары укытучылар тарафыннан әзерләнә. Темалар кафедра утырышында карала һәм факультет советында раслана.

Тема сайлау бик җаваплы мәсьәлә. Курс эше темасын да чыгарылыш квалификация эше темасы дәрәҗәсендә үстерергә мөмкин. Тема артык тар яки артык киң булырга тиеш түгел, шулай ук аның актуальлегенә дә игътибар итәргә кирәк.

Чыгарылыш квалификация эше темасы татар тел гыйлеменең һәм әдәбиятның төрле өлкәләренә багышлана ала. Мәсәлән, тел гыйлеменнән фонетика, лексикология, сүзьясалышы һәм грамматика (морфология һәм синтаксис) тармакларына, әдәбияттан төрле чорларга караган темалар булырга мөмкин. Фәнни эш темасы артык тар яки артык киң булырга тиеш түгел.

Тема тәкъдим иткән вакытта аның мәктәптәге уку-укыту процессы белән бәйләнешенә дә игътибар итү сорала, чөнки эш белем алучының киләчәктәге укытучылык хезмәте белән бәйләнгән булырга тиеш.

Темалар расланганнан соң, белем алучы тәкъдим ителгән исемлектән тема сайлый. Чыгарылыш квалификация эшен башкару ЮББ ФДБМУ “Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты”нда белем алучыларның фәнни-тикшеренү эшләренең нормоконтроле турындагы нигезләмәгә (Положение о нормоконтроле научно-исследовательских работ обучающихся в ФГБОУ ВО “Набережночелнинский государственный педагогический университет”) таянып башкарыла.

Хезмәткә керешер алдыннан чыгарылыш квалификация эшенең календарь планы эшләнә.

## 2. Хезмәтне язу барышында материаллар туплау

Чыгарылыш квалификация эшен башкарганда материаллар туплау, аларны тиешле тәртипкә салу тикшеренүчедән билгеле бер эш күнекмәләрен таләп итә. Димәк, фәнни хезмәтне язу барышындагы мөһим мәсьәләләрнең берсе – төрле чыганаклар белән эшли белү. Белем алучылар түбәндәге чыганакларга мөрәҗәгать итә алалар:

-әдәби чыганаклар (мәсәлән: поэзия һәм проза, драма әсәрләре, халык авыз иҗаты үрнәкләре һ.б.);

-норматив-хокукый чыганаклар;

-дәреслекләр, монографияләр һ.б.

-диссертациялёр һәм диссертация авторефератлары;

-вакытлы матбугат басмалары;

-электрон чыганаклар.

Чыгарылыш квалификация эшен язу барышында белем алучылар архив һәм музей материалларын да кулланырга мөмкиннәр. Бу аеруча әдәбият, ономастика (топонимика) һәм диалектология өлкәләрендә отышлы.

## 3. Чыгарылыш квалификация эшенең структурасына карата куелган таләпләр

Фәнни-тикшеренү эшенең структур элементларына түбәндәгеләр карый:

-чыгарылыш квалификация эшенең тышлыгы (титул бите);

-эчтәлек;

-кереш;

-аерым бүлекләрдән (2-3 бүлек) гыйбарәт төп өлеш;

-йомгак;

-кулланылган чыганаклар исемлеге;

-кушымталар;

-чыгарылыш квалификация эшен башкаруның календарь графигы.

Хезмәтнең һәрбер структур элементы яңа биттән башлана. “Эчтәлек”, “Кереш”, “Йомгак”, “Кулланылган чыганаклар исемлеге”, “Кушымта” кебек структур элементлар юлның уртасында урнаша. Атамалар текстан ике интервал белән аерыла һәм саннар куелмый. Әлеге шарт бүлекчәләргә кагылмый.

3.1 Чыгарылыш квалификация эшенең тышлыгы.

3.1.1 Чыгарылыш квалификация эше тышлыгы фәнни-тикшеренү эшенең беренче бите санала, ләкин бит саны куелмый. Ул рус һәм татар телләрендә эшләнә.

3.1.2 Тышлыкта түбәндәге мәгълүматлар урын ала:

-министрлык исеме;

-университет исеме, шул исәптән кыскартылма формада;

-факультет исеме;

-кафедра исеме;

-фәнни-тикшеренү эшенең төре (чыгарылыш квалификация эше);

-чыгарылыш квалификация эшенең темасы;

-белгечлек саны (шифр) һәм исеме / әзерлек юнәлеше;

-кафедра мөдиренең яклауга рөхсәте, аның гыйльми дәрәҗәсе һәм вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары һәм имзасы;

-фәнни-тикшеренү эше белән җитәкчелек итүченең гыйльми дәрәҗәсе һәм вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары һәм имзасы;

-белем алучының фамилиясе, инициаллары һәм имзасы, төркем саны;

-эш башкарылган шәһәр исеме һәм хезмәт язылган ел (дата).

3.2 Эчтәлек.

Эчтәлектә чыгарылыш квалификация эшенең структур элементлары, аларның бите күрсәтелә.

3.3 Кереш өлеш.

Кереш өлештә түбәндәгеләр күрсәтелә:

-хезмәтнең актуальлеге исбатлана;

-теманың өйрәнелү дәрәҗәсе;

-фәнни эшнең гомумтеоретик нигезләре (әлеге өлкәдә эшләгән авторларның хезмәтләре);

-максат һәм бурычлар;

-тикшеренүләрнең объекты һәм предметы;

-автор тарафыннан кулланылган метод-алымнар;

-эшнең фәнни яңалыгы;

-теоретик-гамәли әһәмиятен дәлилләү;

-хезмәтнең аерым өлешләрен сынап карау (апробация);

-дипломалды практикасы базасы;

-эшнең структурасы.

3.4 Төп өлеш.

Төп өлеш бүлекләрдән тора (2-3 бүлек), ә бүлекләр исә үз чиратында аерым бүлекчәләргә бүленә. Бүлекләр яңа биттән башлана. Бүлек исемнәре текстан ике интервал белән аерыла һәм саннар куела. Һәрбер бүлек төп максатка ирешү юлында конкрет бер мәсьәләне чишүгә корыла һәм кыскача нәтиҗәләр ясау белән төгәлләнә. Бүлекләр бер-берсеннән аерымланган хәлдә яши алмыйлар. Аларда күтәрелгән проблемалар арасындагы фәнни эзлеклелекне саклау шарт.

Фәнни эшнең беренче бүлеген, гадәттә, анализ өлеше тәшкил итә, ә икенче бүлек методика белән бәйләнгән була.

Әйтик, хезмәт тел өлкәсенә багышланган очракта, беренче бүлектә мәсьәләне өйрәнү тарихы урын алырга, әсәрдән мисаллар туплау һәм анализлау эше башкарылырга мөмкин. Белем алучы мисалларны җыйнап кына калмый, ә аларны төркемчәләргә бүлә, әсәрнең эчтәлеге белән бәйләнештә карый.

Икенче бүлек төп һәм гомуми белем бирү этапларындагы уку-укыту процессы белән бәйләнгән булырга тиеш. Биредә тупланган материалны татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә файдалану юллары өйрәнелә, заманча технологиялр кулланып укыту мәсьәләләре карала. Белем алучы эш барышында предметара бәйләнешләргә, тәнкыйди фикерләү технологиясен һәм проектлар эшчәнлеге методын кулланып укыту кебек мәсьәләләргә мөрәҗәгать итә ала.

Бүлекләр бүлекчәләрдән тора. Бүлекчәләр икедән дә ким булмаска тиеш. Һәр бүлекчә нинди дә булса бурычны хәл итүгә багышлана. Бүлекчә ахырында да кыскача нәтиҗәләр ясала.

3.5 Йомгак.

Фәнни тикшеренү эшенә йомгак ясау аеруча зур осталык сорый. Ул төпле һәм ныклы уйланылган булырга тиеш. Йомгак, кереш өлеш кебек үк, күп сүзле була алмый, чөнки анда конкрет фәнни һәм гамәли нәтиҗәләр ясала.

3.6 Кулланылган чыганаклар исемлеге. Кулланылган чыганаклар исемлеге – библиографик аппарат элементы. Аңарда хезмәттә кулланылган чыганакларның тасвирламасы бирелә. Ул йомгаклау өлешеннән соң урнаштырыла. Барлык хезмәтләрнең дә тулы битләре саны күрсәтелә.

Фәнни хезмәттә чыганаклар исемлеген төзүнең түбәндәге юлларыннан файдаланалар: авторларның фамилияләре яки хезмәт исемнәре әлифба һәм хронологик тәртип буенча бирелә. Мәсәлән:

Зәкиев, М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек / М.З.Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2008. – 399 б.

Хаҗиев, Р.И. Ата-бабаларыбыз мирасы / Р.И. Хаҗиев. – Яр Чаллы: ЧДПИ нәшрияты, 2010. – 203 б.

Хисамова, Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек / Ф.М.Хисамова. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.

Чыгарылыш квалификация эшен язу барышында кулланылган чыганаклар 25тән дә ким булмаска тиеш.

3.7 Кушымта.

Хезмәтләрдә кушымтадан файдалану аларның гамәли әһәмиятен тагын да арттыра төшә. Ул бер яки берничә булырга мөмкин.

Кушымта төрле характерда була ала. Мәсәлән, дәреснең технологик картасы, фәнни-тикшеренү эшен үтәү барышында эшләнгән күрсәтмәләр, сүзлекләр һ.б. Форма ягыннан алар текст, таблица, диаграмма рәвешендә булырга мөмкин.

Кушымта чыгарылыш квалификация эшенең дәвамы рәвешендә, аның ахыргы битләрендә бирелә.

Һәрбер кушымта яңа биттән башланырга тиеш. Бит өстенә “Кушымта” дип куела һәм аның исеме күрсәтелә. Берничә кушымта булганда алар хәрефләр белән билгеләнә, мәсәлән:

Кушымта 1

Исеме

Кушымта 2

Исеме

Кушымталарда бит саны күрсәтелә.

## 4.Сылтама һәм астөшермәләрне күрсәтү тәртибе

*1) Текст эчендәге сылтамага мисал:*

Татар телендә сүзьясалышының түбәндәге ысуллары бар: 1) фонетик ысул; 2) кушымчалау ысулы; 3) сүзләр кушылу; 4) сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе; 5) сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе; 6) конверсия (лексик-грамматик ысул); 7) лексик-семантик ысул; 8) аббревиация (кыскартылмалар ясалышы). Кушымчалау, сүзләр кушылу, сүзтезмәләрнең кушма сүзгә күчү ысуллары иң продуктив ысуллар булып тора. Конверсия һәм лексик-семантик ысуллар ул кадәр үк продуктив түгелләр [5, б. 14].

Димәк, әлеге сылтама материалның “Кулланылган чыганаклар исемлеге”ндә (шартлы рәвештә) 5 нче чыганак булып урнашкан хезмәттән алынган булуын хәбәр итә. Мәсәлән:

Ганиев, Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы / Ф.Ә. Ганиев. – Казан: Мәгариф, 2006. – 271 б.

*2) Астөшермәгә мисаллар:*

Актаныш авылы территориясенә кешеләр моннан 300-400 ел элек күчеп утырганнар. Авыл башта хәзерге Норкә урманының көньяк-көнчыгыш өлешенә урнашкан булган. Авыл атамасы авыл эченнән ага торган Актаныш елгасы исеменнән алынган[1].

*Шул ук хезмәттән кабат  файдаланган очракта:*

Агалы-энеле Ирмәш һәм Шәриф исемле ике туган килеп төпләнер өчен урман эзләп йөргәннәр. Һәм көннәрдән бер көнне бик матур бер җиргә килеп чыкканнар. Якында гына Агыйдел елгасы аккан. Бер ягында тау, икенче ягында күл җәелеп яткан. Ирмәш дигәненә бу урын бик ошаган һәм ул шушында төпләнеп калган. Шуннан бирле авыл аның исемен йөртә. Ә Шәриф исемлесе Шәриф авылын нигезләгән[2].

---

[1] Гарипова, Ф.Г. Аккошлар иле – Актанышка сәяхәт / Ф.Г. Гарипова. – Казан: “Идел-Пресс” ПНК “ТАТМЕДИА” ААЖ, 2010. – Б. 72. [2] Шунда ук, Б. 76.

Белем алучы эштә кулланылган материалларга, фәнни чыганакларга сылтамалар күрсәтелүе турында белешмә дә бирә.

**5. Хезмәттә кулланылган чыганаклар исемлеген күрсәтү**

*1) Китаптан алынган материаллар Бер автор булганда:*

Харисова, Ч.М. Татар теле: морфемика, сүз ясалышы, морфология. Уку-укыту кулланмасы / Ч.М. Харисова. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2018. – 231 б.

Хәкимҗан, Ф.С. Татар әдәби теле: Фонетика: Югары уку йортлары студентлары өчен / Ф.С. Хәкимҗан. – 3 нче басма. – Казан: Gumanitarya, 2005. – 108 б.

*Берничә автор булганда:*

Заһидуллина, Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йорты студентлары өчен кулланма / Д.Ф. Заһидуллина, М.И. Ибраһимов, В.Р. Әминева. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.

*2) Алдан китап исеме күрсәтелгән очракта*

Татар лексикологиясе: 3 томда / проект җитәкчесе М.З. Зәкиев; редакторы Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘҺСИ, 2015. – Т.1 – 352 б.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту / төзүчеләр Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова. – Яр Чаллы, 2015. – 52 б.

*3) Энциклопедия һәм сүзлектән алынган материаллар:*

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: ТӘҺСИ, 2015. – Т.1. – 712 б.

*4) Газета-журнал материаллары:*

Моталлапов, Ә. Гаилә // Ә. Моталлапов // Казан утлары. – 2019. – № 11. – Б. 127-138.

Шәфыйков, Я. Актанышка кайта юлларым / Я. Шәфыйков // Шәһри Чаллы. – 2006. – 17 нче гыйнвар.

*5) Конференция материаллары:*

Хаҗиев, Р.И. Мөслим авылы / Р.И. Хаҗиев // Прикамский регион: география, история и культура: Материалы Всероссийской научнопрактической конференции (18-19 апреля 2013 г.): Сборник научных трудов. – Набережные Челны: НИСПТР, 2013. – С. 234-235.

*6) Диссертация һәм автореферат материаллары:*

Хисамов, О.Р. Историко-лингвистический анализ ойконимии Западного Закамья Татарстана: автореф. дис. канд. филол. наук / О.Р. Хисамов. – Казань: КГУ, 2001. – 21 с.

## 6. Хезмәтне техник яктан дөрес оештыру

Хезмәт А-4 форматлы стандарт кәгазьнең бер ягында, юллар арасында 1,5 интервал калдырылып, 14ле шрифт (Word) белән компьютерда бастырыла. Шрифт – Times New Roman. Битләрдә сул яктан 30 мм, уңнан 10 мм, өстән һәм астан 20 мм ара калдырыла. Кызыл юл – 12,5 мм.

Бит саны өстә, уртада күрсәтелә.

Чыгарылыш квалификация эшенең күләме 45 биттән дә ким булмаска тиеш.

## 7. Нормоконтроль уздыру тәртибе

Нормоконтроль чыгарылыш квалификация эшен башкару процессының төгәлләү этабы булып тора.

Фәнни хезмәтләрне нормоконтрольгә тәкъдим иткән вакытта җаваплы кешеләрнең (белем алучы һәм җитәкченең) имзалары булу сорала (кафедра мөдиреннән тыш).

Нормоконтроль кафедра мөдире яки аның тарафыннан билгеләнгән җаваплы зат тарафыннан уздырыла.

Нормоконтролер ЮББ ФДБМУ “Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты”нда белем алучыларның фәнни-тикшеренү эшләренең нормоконтроле турындагы нигезләмәгә таяна.

Нормоконтроль вакытында эштә күзәтелгән җитешсезлекләргә игътибар ителә. Хезмәттә күзәтелгән кимчелекләр нормоконтроль битендә күрсәтелә.

Куелган таләпләргә җавап бирмәгән очракта, искәртелгән кимчелекләрне төзәтү өчен, хезмәт белем алучыга кире кайтарыла.

Моның берничә сәбәбе булырга мөмкин:

-хезмәтне башкару тәртибе үтәлмәгән очракта;

-чыгарылыш квалификация эшен “Антиплагиат.ВУЗ” системасы аша тикшергәнлеккә справка булмаса;

-тиешле имзалар булмаса;

-текст һәм график материаллар эшләнешендә җитешсезлекләр күзәтелсә.

Чыгарылыш квалификация эшләрендә күзәтелгән кимчелекләр һәр уку елы ахырындагы кафедра утырышында карала.

Хезмәттә рецензия, җитәкче бәяләмәсе кебек документлар һәм эшнең электрон варианты булырга тиеш.

**Тәкъдим ителгән чыганаклар**

1. Галләмов, Ф.Г. Курс һәм чыгарылыш квалификация эшләрен язу методикасы / Ф.Г. Галләмов. – Алабуга: АДПУ нәшрияты, 2008. – 36 б.

2. Мөхиярова, Р.Х. Татар теле, әдәбияты һәм аларны укыту методикасы буенча курс һәм диплом эшләре (студентлар өчен методик кулланма) / Р.Х. Мөхиярова. – Яр Чаллы, 2003. – 24 б.

3. Мусин, А.Г. Методические рекомендации по выполнению дипломных работ / А.Г. Мусин. – Набережные Челны, 2001. – 22 б.

4. Положение о нормоконтроле научно-исследовательских работ обучающихся в ФГБОУ ВО "Набережночелнинский государственный педагогический университет". – Набережные Челны: НГПУ, 2016.

5. Хаҗиев, Р.И. Татар ономастикасы буенча чыгарылыш квалификация (диплом) эшләре (югары уку йорты студентлары өчен методик кулланма) / Р.И. Хаҗиев. – Яр Чаллы: "Яр Чаллы типографиясе" ААҖ, 2006. – 20 б.